СОВЕТ БУТЛЕРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БУТЛЕРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«15» августа 2022 г. с. Мокрые Курнали № 31

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 2004 елның 29 декабрендәге 190 – ФЗ номерлы 31 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пунктына таянып,

**Бутлеровка авыл җирлеге советы карар итте:**

1. Бутлеровка авыл җирлеге Советының 24.04.2013 ел, №69а «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
Территориаль зона **Ж1 – шәхси торак төзелеше зонасы,** җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның **түбәндәге төп төрләре** белән тулыландырырга: авыл хуҗалыгы кулланышы; шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен; торак төзелеше; шәхси торак төзелеше өчен; блокланган торак төзелеше; күчмә торак; урта катлы торак төзелеше; автотранспортны саклау; үз ихтыяҗлары өчен гаражлар урнаштыру; элемтә хезмәте күрсәтү; көнкүреш хезмәте күрсәтү; сәламәтлек саклау; эшмәкәрлек; спорт; яшелчәчелек алып бару; бакчачылык алып бару.
Территориаль зона **ОД1 - күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона,** җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның **түбәндәге төп төрләре** белән тулыландырырга: авыл хуҗалыгы кулланышы; питомниклар; автотранспортны саклау; капиталь төзелеш объектларыннан җәмәгатьчелек тарафыннан файдалану; коммуналь хезмәт күрсәтү; коммуналь хезмәтләр күрсәтү; коммуналь

хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүче оешмаларның административ биналары; социаль хезмәт күрсәтү; социаль хезмәт күрсәтү йортлары;халыкка социаль ярдәм күрсәтү; элемтә хезмәте күрсәтү; тулай торак; көнкүреш хезмәте күрсәтү; сәламәтлек саклау; мәгариф һәм белем бирү; мәдәни үсеш; фәнни эшчәнлекне тәэмин итү; эшмәкәрлек; эшлекле идарә; сәүдә объектлары (сәүдә үзәкләре, сәүдә-күңел ачу үзәкләре (комплекслар); базарлар; кибетләр; банк һәм иминият эшчәнлеге; җәмәгать туклануы; кунакханә хезмәте күрсәтү; күңел ачу;күңел ачу чаралары; күңел ачу чаралары; хезмәт урыны гаражлары; автомобиль юу урыннары; автомобильләрне ремонтлау; спорт; элемтә; фәнни-җитештерү эшчәнлеге.

3. Территориаль зона **СХ1 – авыл хуҗалыгы җирләре зонасы** җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның **түбәндәге төп төрләре** белән тулыландырырга: авыл хуҗалыгы кулланышы; үсемлекчелек; бөртекле һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын үстерү; яшелчәчелек; тонизацияли торган, дару, чәчәк культуралары үстерү; бакчачылык; йөзем үстерү; җитен һәм киндер үстерү; терлекчелек; эре терлекчелек; җәнлекчелек; кошчылык; дуңгызчылык; умартачылык; балык үрчетү; авыл хуҗалыгын фәнни яктан тәэмин итү;  авыл хуҗалыгы продукциясен саклау һәм эшкәртү; кыр шартларында шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару; питомниклар; авыл хуҗалыгы җитештерүен тәэмин итү; печән чабу; авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү; эчке хокук тәртибен тәэмин итү; яшелчәчелек алып бару; бакчачылык алып бару.

Территориаль зона **СХ2 – авыл хуҗалыгы предприятиеләрен һәм корылмаларын урнаштыру зонасы** җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның **түбәндәге төп төрләре** белән тулыландырырга: авыл хуҗалыгы кулланышы; үсемлекчелек; бөртекле һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын үстерү; яшелчәчелек; тонизацияли торган, дару, чәчәк культуралары үстерү; бакчачылык; йөзем үстерү; җитен һәм киндер үстерү; терлекчелек; эре терлекчелек; җәнлекчелек; кошчылык; дуңгызчылык; умартачылык;  балык үрчетү; авыл хуҗалыгын фәнни тәэмин итү; авыл хуҗалыгын фәнни яктан тәэмин итү; авыл хуҗалыгы продукциясен саклау һәм эшкәртү;кыр шартларында шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару; питомниклар; авыл хуҗалыгы җитештерүен тәэмин итү; печән чабу; авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү; эчке хокуый тәртипне тәэмин итү; яшелчәчелек алып бару; бакчачылык алып бару.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.
4. Карар халыкка рәсми рәвештә җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге Башлыгы, Совет Рәисе** **И.Л. Хушанова**